| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОКЫРЛАЙСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,<br>Арский муниципальный район, 422035 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА КЫРЛАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422035 |

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**«31» октябрь 2022 ел** **№4**

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Пионер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 маддәсе нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Пионер авылы, Үзәк урам, 3 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 14 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Пионер авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү күләме 2000 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 100 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау Җиңүнең 65 еллыгы урамы 4 йортыннан 7 йортына кадәр-50м.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Пионер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына Татарстан Республикасы , Арча районы, Пионер авылы, 6 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ